**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2598**
**15.04.2021**

Башкарма комитетның 2007 елның 29 маендагы 1978 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны карау һәм саклау кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренең 56 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2007 елның 29 маендагы 1978 номерлы карары (Башкарма комитетның 2007 елның 14 августындагы 2924 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 3238 номерлы, 2020 елның 11 февралендәге 590 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмаларны карау һәм саклау кагыйдәләренең 8.1 пунктына, аңа түбәндәге эчтәлектәге җөмлә өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«Агачларны һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына – Россия Федераль салым хезмәтенә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмаганда бирелә».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов